ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

25.07.2023 с.Старое Дрожжаное № 306

Чүпрәле муниципаль районының район үзәге - Иске Чүпрәле авылыннан 11 км ераклыкта урнашкан Чүпрәле муниципаль районының ерак һәм аз торак пунктларына беренче чиратта кирәкле товарларны китерү белән бәйле кулланучылар кооперациясе оешмаларына чыгымнарының бер өлешен каплау өчен Чүпрәле муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү Тәртибенә үзгәреш кертү турында

«Субсидияләр бирүне җайга сала торган норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантлар бирүне, юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга, шулай ук физик затларга - товарлар, эшләр, хезмәтләр җитештерүчеләргә гомуми таләпләргә үзгәрешләр кертү турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2022 елның 22 декабрендәге 2385 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 16 октябрендәге 471 номерлы (17.11.2020 № 605, 14.01.2021 № 3, 25.01.2022 № 46, 15.11.2021 № 497, 25.03.2022 № 164, 04.08.2022 № 402 редакциясендә) карары белән расланган Чүпрәле муниципаль районы үзәгеннән 11 километр ераклыкта урнашкан Чүпрәле муниципаль районының ерак һәм аз торак авыл пунктларына товарларны китерү белән бәйле кулланучылар кооперациясе оешмаларының чыгымнар өлешен каплау өчен Чүпрәле муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә.

**2.7 пунктның бишенче абзацы** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Сайлап алуда катнашучылар Россия Федерациясендә активлар белән арадаш (офшор) биләү өчен кулланыла торган дәүләтләрнең һәм территорияләрнең устав (җыелма) капиталында офшор компанияләрнең турыдан-туры яисә читләтеп катнашу өлеше 25 проценттан артмаган (әгәр Россия Федерациясе законнарында башкасы каралмаган булса) Россия Федерациясе Финанс министрлыгы раслый торган исемлеккә кертелгән чит ил юридик затлары (шул исәптән дәүләт яисә территория) булырга тиеш түгел. Офшор компанияләренең Россия юридик затлары капиталында катнашу өлешен капиталында катнашу өлешен исәпләп чыгарганда акцияләре Россия Федерациясендәге оештырылган торгларда әйләнештә йөри торган гавами (шул исәптән халыкара компания статусы булган) акционерлык җәмгыятьләре капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры һәм (яки) турыдан-туры булмаган катнашуы, шулай ук мондый офшор компанияләренең башка Россия юридик затлары капиталында әлеге гавами акционерлык җәмгыятьләре капиталында катнашып тормышка ашырылган турыдан-туры булмаган катнашуы исәпкә алынмый».

2. Әлеге карарны Чүпрәле муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.И. Мөхәммәтҗанов